Исполнительный комитет
Бизякинского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан
ул. Центральная д. 46, с. Бизяки
Менделеевский район, 423648

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә
авыл җирлеге башкарма комитеты
Үзәк урам, 46, Бәзәкә авылы,
Менделеевск районы, 423648

тел./факс (85549)3-47-34

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.03.2024 ел №38

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
"Бәзәкә авыл җирлеге" территориясендә урнашкан
кадастр номерлары 16:27: 070801:699, 16:27:070901:150
булган җир кишәрлекләренә
территорияне планлаштыру проекты буенча
ачык тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Бәзәкә авыл җирлеге уставы, гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында 2024 елның 18 апрелендә 16 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча Менделеевск районы, Бәзәкә авылы, Үзәк ур., 46 йорт, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы "Бәзәкә авыл җирлеге" территориясендә урнашкан кадастр номерлары 16:27: 070801:699, 16:27:070901:150 булган җир кишәрлекләренә территорияне планлаштыру проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

И.И. Кәшәфетдинов - Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе;

Садриев М.Ф. - Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге рәисе урынбасары;

И.Р. Кәшафетдинов - Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге депутаты (килешү буенча).

3. 2024 елның 18 мартыннан 18 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы "Бәзәкә авыл җирлеге" территориясендә урнашкан кадастр номерлары 16:27: 070801:699, 16:27:070901:150 булган җир кишәрлекләренә территорияне планлаштыру проекты буенча материаллар экспозициясен Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, Менделеевск районы, Бәзәкә авылы, Үзәк урам, 46 йортында оештырырга

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә (җибәрелә): 432648, Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Бәзәкә авылы, Үзәк ур.,

46 йорт (Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы исеменә).

5. Әлеге карарны Бәзәкә авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштырып игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында ww.mendeleevsk.tatar.ru "Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И.Кәшәфетдинов